**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Порядок подготовки, опубликования и вступления в силу актов Президента Республики Татарстан, представления Президенту Республики Татарстан проектов законов Республики Татарстан

1. Внести в Порядок подготовки, опубликования и вступления в силу актов Президента Республики Татарстан, представления Президенту Республики Татарстан проектов законов Республики Татарстан, утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 2 июня 2004 года № УП-431 «О порядке подготовки, опубликования и вступления в силу актов Президента Республики Татарстан, представления Президенту Республики Татарстан проектов законов Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 12 июля 2010 года № УП-445, от 5 октября 2011 года № УП-622, от 14 августа 2014 года № УП-788, от 20 февраля 2015 года № УП-178 и от 8 июля 2016 года № УП-585), следующие изменения:

а) в пункте 1 слова «предприятий, учреждений и» исключить, слова «Уполномоченный при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей» заменить словами «Уполномоченный при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей – помощник Президента Республики Татарстан»;

б) пункты 11–13 изложить в следующей редакции:

«11. Имеющие нормативный характер указы Президента Республики Татарстан официально публикуются на государственных языках Республики Татарстан в течение 10 дней после дня их издания. Не имеющие нормативного характера указы Президента Республики Татарстан и распоряжения Президента Республики Татарстан могут быть официально опубликованы в порядке и сроки, предусмотренные для указов Президента Республики Татарстан, имеющих нормативный характер. При официальном опубликовании актов Президента Республики Татарстан указываются наименование указа или распоряжения, должностное лицо, его подписавшее, место и дата его издания, регистрационный номер.

Официальным опубликованием имеющих нормативный характер указов Президента Республики Татарстан считается первая публикация их полных текстов в газетах «Республика Татарстан» и «Ватаным Татарстан», журнале «Собрание законодательства Республики Татарстан» или первое размещение

(опубликование) на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU) либо на «Официальном интернет-портале правовой информации» (www.pravo.gov.ru).

Имеющие нормативный характер указы Президента Республики Татарстан подлежат размещению на официальном сайте Президента Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в сроки, предусмотренные для их официального опубликования.

Указы и распоряжения Президента Республики Татарстан могут быть опубликованы в иных печатных изданиях, помимо указанных в абзаце втором настоящего пункта, а также доведены до всеобщего сведения (обнародованы) по телевидению и радио, разосланы государственным органам, органам местного самоуправления, должностным лицам, организациям, переданы по каналам связи, распространены в машиночитаемой форме.

12. Не подлежат опубликованию имеющие нормативный характер указы Президента Республики Татарстан или отдельные их положения, содержащие сведения, составляющие государственную тайну, и иные сведения, не подлежащие разглашению в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

13. Имеющие нормативный характер указы Президента Республики Татарстан вступают в силу со дня их официального опубликования, если данными актами не предусмотрен иной порядок вступления их в силу.

Имеющие нормативный характер указы Президента Республики Татарстан, затрагивающие права и свободы человека и гражданина, вступают в силу не ранее чем через 10 дней после дня их официального опубликования.

Не имеющие нормативного характера указы Президента Республики Татарстан, указы Президента Республики Татарстан, содержащие сведения, составляющие государственную тайну, и иные сведения, не подлежащие разглашению в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан, распоряжения Президента Республики Татарстан вступают в силу со дня их издания, если данными актами не предусмотрен иной порядок вступления их в силу.».

2. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
31 октября 2022 года
№ УП-773

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибе турында» 2004 елның 2 июнендәге ПУ-431 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2014 елның 14 августындагы ПУ-788 номерлы, 2015 елның 20 февралендәге ПУ-178 номерлы һәм 2016 елның 8 июлендәге ПУ-585 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «предприятиеләр, учреждениеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 11–13 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Президентының норматив характердагы указлары чыгарылган көннән 10 көн эчендә Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә рәсми рәвештә бастырып чыгарыла. Татарстан Республикасы Президентының норматив характерда булмаган указлары һәм Татарстан Республикасы Президенты боерыклары Татарстан Республикасы Президентының норматив характердагы указлары өчен каралган тәртиптә һәм срокларда рәсми рәвештә бастырып чыгарыла ала. Татарстан Республикасы Президентының актлары рәсми рәвештә бастырып чыгарылганда указның яисә боерыкның атамасы, аңа кул куйган вазыйфаи зат, чыгарылган урыны һәм вакыты, теркәү номеры күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Президентының норматив характердагы указларының рәсми рәвештә бастырып чыгарылуы дип аларның тулы

текстларының «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасының законнар җыентыгы» журналында беренче тапкыр бастырып чыгаруы яисә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) яки «Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштырылуы (бастырып чыгарылуы) санала.

Татарстан Республикасы Президентының норматив характердагы указлары, аларны рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен каралган срокларда, Татарстан Республикасы Президентының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Президентының указлары һәм боерыклары, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка басмаларда бастырылып чыгарылырга, шулай ук гомуми мәгълүмат буларак телевидение һәм радио аша тапшырылырга (халыкка җиткерелергә), дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга, оешмаларга, элемтә каналлары аша җибәрелергә, машина ярдәмендә укыла торган формада таратылырга мөмкин.

12. Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар яисә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка мәгълүматлар булган Татарстан Республикасы Президентының норматив характердагы указлары яисә аларның аерым нигезләмәләре бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

13. Татарстан Республикасы Президентының норматив характердагы указлары, әлеге актларда аларның үз көченә керүенең башка тәртибе каралмаган очракта, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президентының кеше һәм гражданның хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы норматив характердагы указлары алар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң кимендә 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президентының норматив характерда булмаган указлары, дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка мәгълүматлар булган Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Президенты боерыклары, әлеге актларда аларның үз көченә керүенең башка тәртибе каралмаган очракта, бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ / АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 31 октябрь
№ ПУ-773